# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Тымытык авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**11 ноябрь 2025 ел** **№1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принципլары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башлыгының "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"27.10.2025 ел, № 4 карары нигезендә 2025 елның 11 ноябрендә узган Тымытык авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре белән Тымытык авылы гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

« Сез, 2026 елда Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә, 1 нче төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 200 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урам тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар өчен мәйданчыкларны, бүлү нокталарын һәм электр тоташуларын һәм электр энергиясен тапшыруны тәэмин итү өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (энергияне саклаучы лампалар, электр товарлары, махсус җиһазлар һәм башка материаллар сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырту җайланмаларын һәм лампаларын алыштыру, урам яктыртуларын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү );

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (Яшьләр, Бакча, Яналиф урамнары буйлап вак таш сатып алу, төяү, ташу, җәю);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 863 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 512.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен 481, «КАРШЫ» позициясе өчен 31 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

« Сез, 2026 елда Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә, 1 нче төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 200 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урам тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар өчен мәйданчыкларны, бүлү нокталарын һәм электр тоташуларын һәм электр энергиясен тапшыруны тәэмин итү өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (энергияне саклаучы лампалар, электр товарлары, махсус җиһазлар һәм башка материаллар сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырту җайланмаларын һәм лампаларын алыштыру, урам яктыртуларын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү );

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (Яшьләр, Бакча, Яналиф урамнары буйлап вак таш сатып алу, төяү, ташу, җәю);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту)».

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Тымытык авылы, Тельман урамы, 62Б йорт; Тельман ур., 75 нче йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында http://aznakayevo.tatar.ru адресы буенча урнаштырып халыкка чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Мостафина